ҖОМГА
8
ЯНВАРЬ
1943 ел.
№ 6 (6728)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН өлкә һәм КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

Москва, ВКП(б) Үзәк Комитеты, Иосиф Виссарионович СТАЛИНГА

Кадерле Иосиф Виссарионович, Ватаныбызны саклау эшенә Тамбов колхозчылары керткән гади генә ярдәмне—танклар колоннасына 43 миллион сум акча җыюны күрсәтеп үткән Сезнең котлау телеграммагызны Тамбов өлкәсенең барлык почмакларында колхозчылар, колхозчы хатын-кызлар, эшчеләр һәм хезмәткәрләр тирән тәэсирләнү белән, партиягә, Совет хөкүмәтенә һәм Сезгә, совет халкының зирәк һәм куркусыз юлбашчысына һәм полководецына карата чиксез мәхәббәт һәм рәхмәт хисе белән, чиксез ышанганлыкларын аңлау белән тыңладылар. Сезнең котлавыгыз, иптәш Сталин, һәрбер хезмәт иясенең йөрәгендә Кызыл Армиянең изге бурычын—совет җирен фашист оккупантлардан азат итү бурычын үтәүдә аңа ярдәм күрсәтү буенча үзенең тырышлыгын ун өлеш арттырырга ялкынлы омтылыш тудырды. Сез безгә Кызыл Армиянең рәхмәтен белдердегез һәм бу рәхмәтне ун меңнәрчә сугышчылар һәм командирлар Тамбов колхозларына һәм колхозчыларына язган чиксез күп хатларында расладылар. Бу рәхмәт сүзләре хезмәт ияләренең барлык катлауларында явыз фашист кол биләүчеләрне җиңү өчен героик хезмәткә омтылыш тудырды.

Бөтен совет халкының, колачы һәм көче ягыннан гаять бөек булган патриотлык күтәрелеше, Сезнең җылы котлавыгыз аркасында, Тамбов һәм Саратов өлкәләрендәге колхозчы крестьяннарның гади инициативасыннан үсеп чыкты. Бу күтәрелеш Тамбов өлкәсе колхозчыларын һәм колхозчы хатын-кызларын тагын да канатландырды, большевиклар партиясе һәм Совет хөкүмәте җитәкчелегендәге, Сезнең, иптәш Сталин, җитәкчелегегездәге совет халкының көчен бөтен бөеклеге белән күрсәтте.

Сезнең котлавыгызга һәм Кызыл Армиянең рәхмәтенә җавап итеп Тамбов өлкәсе колхозчылары һәм колхозчы хатын-кызлары, эшчеләре һәм хезмәткәрләре, Сезгә, кадерле Иосиф Виссарионович, үзләренең бернинди дә кыенлыклар һәм корбаннар алдында тукталып калмастан, совет халкының намусына һәм совет байлыгына кул сузган актык фашист юк ителгәнчегә кадәр яки совет җиреннән куылганчыга кадәр фронтка ярдәмне туктаусыз арттыра барачакларын белдерүне үтенделәр. Тамбов өлкәсе колхозчылары һәм колхозчы хатын-кызлары Сезгә, иптәш Сталин, биргән бу вәгъдәләрен эш белән беркетәләр. Сезнең котлавыгызны укып чыкканнан соң алар үз акчаларына Кызыл Армиянең 25 еллыгына карата кызыл йолдызлы сугыш истребительләреннән 25 эскадрилья төзергә һәм аларны Кызыл Армиягә тапшырырга карар бирделәр: «Безнең «Тамбов колхозчысы» исемле сугыш эскадрильяләребез, һавадан торып, «Тамбов колхозчысы» исемле танклар колоннасына булышлык итсеннәр һәм, танкистлар белән бергәләп, фашист кычракларны кырсыннар»,—диделәр колхозчылар. 1943 нче елның 1 нче январена колхозчылар һәм колхозчы хатын-кызлар сугыш самолетлары төзелешенә 41 миллион 500 мең сум акча җыйдылар. Шуның өстенә алар планнан тыш Кызыл Армия фондына 214 мең пот ашлык, 59 мең 400 пот бәрәңге һәм яшелчә, 4 мең 700 пот ит, 6 мең 500 данә сарык тиресе, 3 мең килограмм йон керттеләр.

Безнең өлкәбездәге шәһәрләрнең дә хезмәт ияләре акча җыюны гадәттән тыш күтәренкелек белән алып баралар. Алар Кызыл Армиягә аның 25 еллыгы көнендә «Тамбовлы» исемле берничә бронепоезд бирергә телиләр. Хәзергә барлыгы 1 миллион сумнан артык акча җыелды инде. Медицина работниклары санитария самолетлары төзелешенә 1 миллион сумнан артык керттеләр. Акча һәм азык җыю дәвам итә.

Колхозчылар һәм колхозчы хатын-кызлар, эшчеләр һәм хезмәткәрләр тапшыруы буенча без халыкның саклык акчаларына ясалган сугыш машиналарын алган һәм алачак танк һәм авиация частьларына һәм берләшмәләренә өлкәдәге хезмәт ияләренең үзләренең Кызыл Байракларын тапшыруларына Сездән, Иосиф Виссарионович, ризалык сорыйбыз. Бу байраклар сугышчылар өчен халыкның үзенең Кызыл Армиясенә булышлык итүенең даими үрнәге булсыннар. Алар сугышның нинди генә минутында да сугышчылар белән бергә, үзләренең көчләрен кызганмыйча, явыз дошманга каршы аларның аталары һәм балалары, аналары һәм хатыннары, ир һәм кыз туганнары көрәшкәнлекне сугышчыларның исләренә төшерсеннәр. Сугышчылар һәм командирлар бу байракларны сугыш кырлары буйлап тәмам җиңгәнчегә кадәр күтәреп үтсеннәр һәм җиңү көнендә аларны үзләренең җиңү рапортлары белән берлектә, бөек Ватан сугышының авыр елларында халыклар массасының үз Ватанын саклау эшенә чын күңелдән бирелгәнлегенең шаһитләре сыйфатында алып кайтсыннар. Соңыннан бу байраклар безнең балаларыбыз һәм аларның балалары өчен халык батырлыгының мәңгелек истәлеге булып, бөек Ватаныбызның азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен, кешеләребезнең һәм киләчәк буыннарыбызның бәхетле шат тормышы өчен көрәштә совет халкының һәм аның героик армиясенең сугышчан бердәмлегенең мәңгелек истәлеге булып калсыннар.

Тамбов өлкәсе хезмәт ияләреннән ялкынлы сәлам һәм озак, озак еллар сәламәтлек теләвебезне кабул итегез, сөекле иптәш Сталин.

Партия өлкә комитеты секретаре ВОЛКОВ.

ВКП(б) ның Тамбов өлкәсе бюросының һәм хезмәт ияләре депутатларының өлкә советы башкарма комитетының членнары: КОЗЫРЬКОВ, ПАШКИН, ПЛАКХИН, МИТРЯШОВ, БАЛАШОВ, ПОЛЯКОВ, ЖАРИНОВ, СВИНЦОВ, ГАСПАРЯН, МОИСЕЙЦЕВ, ТАРАБАРИН.

ХӘРӘКӘТТӘГЕ АРМИЯ. Рәсемдә: Яшь снайпер Сабир Хәким улы Гумеров. Ул кыска кына вакыт эчендә 22 немецны кырып ташлады.

Х. Зингерман фотосы (ТАСС фотохроникасы).

ТАМБОВ ШӘҺӘРЕ

ВКП(б) ның Тамбов өлкә комитеты секретаре иптәш ВОЛКОВКА

Тамбов өлкәсенең моннан элек җыелган 43 миллион сум өстенә «Тамбов колхозчысы» исемле самолетлар эскадрильяләре төзелешенә 41 миллион 500 мең сум җыйган, дәүләт йөкләмәләрен үтәгәннән соң Кызыл Армия фондына 214 мең пот ашлык, бәрәңге, яшелчә, ит, сарык тиресе һәм йон керткән колхозчыларына һәм колхозчы хатын-кызларына, шулай ук Тамбов өлкәсе шәһәрләренең «Тамбовлы» бронепоездлары төзелешенә 1 миллион сумнан артык акча җыйган хезмәт ияләренә, санитария самолетлары төзелешенә 1 миллион сумнан артык акча керткән медицина работникларына минем туганлык сәламемне һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшырыгыз.

И. СТАЛИН.

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ ЛИЧНЫЙ СОСТАВЫ ӨЧЕН ЯҢА АЕРЫМЛЫК БИЛГЕЛӘРЕ КЕРТҮ ТУРЫНДА

1. Оборона Халык Комиссариатының үтенечен канәгатьләндерергә һәм Кызыл Армиянең личный составы өчен хәзерге аерымлык билгеләре урынына яңа билгеләр—погоннар кертергә.

2. Кызыл Армиянең личный составының яңа аерымлык билгеләренең үрнәкләрен һәм язма аңлатмасын расларга.

3. СССР Оборона Халык Комиссарына,—яңа аерымлык билгеләренә күчү срокларын билгеләргә һәм Кызыл Армиянең личный составының кием формасына кирәкле үзгәрешләрне кертергә.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва, Кремль, 6 январь, 1943 ел.

Кызыл Армиягә яңа танклар һәм самолетлар

Советлар Союзының хезмәт ияләре, иптәш Сталинның Бөек Октябрь революциясенең 25 еллыгы көнендә сөйләгән доклады белән рухланып, үзләренең саклык акчаларын Кызыл Армия өчен танклар һәм самолетлар төзүгә бирәләр.

Халыклар юлбашчысы иптәш Сталин исеменә түбәндәге телеграммалар алынды:

Королев исемендәге заводның (Иваново шәһәре) цех механигы Алексей Яковлевич Бекасовтан. Ул 10.000 сум керткән.

Главвостокрыбпром (Хабаровск шәһәре) инженеры Андрей Александрович Прибыльскийдан. Ул 10.000 сум керткән.

Серафима Михайловна Трошинадан (Свердловск шәһәре). Ул 10.000 сум кертте.

Фронтовиклар хатыннары Клавдия Волкова һәм Мария Абросимовадан (Иваново шәһәре). Алар акчалата 1.000 сум һәм дәүләт заемы облигацияләре белән 4.000 сум керткәннәр.

2.000 сум акча керткән Мария Васильевна Милавинадан.

Комсомолның Саратов өлкә комитеты секретаре иптәш Ракушиннан. Ул Саратов өлкәсе комсомолецларының һәм яшьләренең танклар колоннасы төзүгә 2.556.000 сум һәм «Саратов комсомолецы» исемле авиаэскадрильяләр төзүгә 3.360.000 сум керткәнлекләрен хәбәр итә.

273.000 сум акча керткән священник Владимир Александрович Стефановтан.

Александр Иванович Козловтан (полевая почта 856, часть 412). Ул 3.000 сум керткән.

Пермь тимер юлының Чусовский бүлеге политбүлегенең начальнигы иптәш Деркачтан. Ул бүлек эшчеләренең, хезмәткәрләренең һәм инженер-техник работникларының 250 мең сум керткәнлекләре турында хәбәр итә.

(ТАСС).

Совет студентлары делегациясе АКШ тан һәм Бөек Британиядән кайтты

Совет студентлары делегациясе—Ватан сугышында катнашучылар—Николай Красавченко, Владимир Пчелинцев һәм Людмила Павличенко иптәшләр, АКШ та һәм Бөек Британиядә дүрт ай вакыт булганнан соң, шушы көннәрдә Москвага кайттылар.

Совет яшьләренең вәкилләре студентларның Вашингтонда үткәрелгән халыкара съездында һәм Лондонда үткәрелгән халыкара конференциясендә актив катнаштылар. Красавченко, Пчелинцев һәм Павличенко иптәшләр Ак йортта АКШ президенты Рузвельт тарафыннан кабул ителделәр.

Делегация дүрт ай вакыт эчендә, СССР белән дус булган илләрдәге яшьләрнең тормышлары, хезмәтләре һәм фашизмга каршы сугышта катнашулары белән якыннан танышты. (ТАСС).

КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ ХӘРБИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНЕҢ ЯҢА АЕРЫМЛЫК БИЛГЕЛӘРЕНӘ КЫСКАЧА ЯЗМА АҢЛАТМА

I. ГОМУМИ МӘГЪЛҮМАТЛАР

Аерымлык билгеләре—погоннар—хәрби хезмәткәрләрнең хәрби дәрәҗәләрен һәм нинди гаскәр төрендә хезмәттә булуларын билгеләү өчен хезмәт итәләр.

Погоннар ике төрле: кыр погоннары һәм көндәлек погоннар булалар. Кыр погоннарының төп аермасы, гаскәрләрнең төренә (хезмәткә) карамастан, погоннарның хаки төсендә булуларында.

Кыр погоннарының һәм көндәлек погоннарның, түбәнге кырыеннан башка кырыйлары төсле сукнодан кант белән әйләндереп алынган.

Бирелгән хәрби дәрәҗәгә, гаскәрләрнең кайсы төрендә (нинди хезмәттә) торуга карап, погоннарга аерымлык билгеләре (йолдызлар, просветлар, нашивкалар) һәм эмблемалар куела, ә кече командирлар, рядовойлар составының һәм хәрби училище курсантларының көндәлек погоннарында гаскәри частьның (берләшмәнең) исемен күрсәтә торган трафаретлар да була.

Генералларның һәм пехотадагы бөтен личный составның кыр погоннары һәм көндәлек погоннары—эмблемасыз. Медицина һәм ветеринария хезмәте генералларының һәм хәрби юридик хезмәттәге югары дәрәҗәле начальниклар составының кыр погоннары һәм көндәлек погоннары—эмблемалар белән.

II. СОВЕТЛАР СОЮЗЫ МАРШАЛЛАРЫНЫҢ ҺӘМ ГЕНЕРАЛЛАРНЫҢ ПОГОННАРЫ ҺӘМ АЕРЫМЛЫК БИЛГЕЛӘРЕ

Погон үзе махсус рәвештә тукылган галуннан тора; кыр погоннары хаки төсендәге ефәктән, көндәлек погоннар алтын волокадан ясала, ә медицина һәм ветеринария хезмәте генераллары өчен—көмеш волокадан.

Советлар Союзы Маршалы, гомуми гаскәрләр генералы, артиллерия генералы, танк гаскәрләре, медицина һәм ветеринария хезмәте генералы погоннарының кантлары кызыл төстә; авиация генералы погоныныкы—зәңгәр төстә; техник гаскәрләр һәм интендантлык хезмәте генераллары погоныныкы—малиновый төстә.

Генералларның погоннарындагы йолдызлар алтын фонга көмеш белән, көмеш фонга алтын белән чигелгәннәр, йолдызларның саны хәрби дәрәҗәләргә туры килә.

Погоннардагы төймәләр алтынланган һәм герблы булалар.

Медицина хезмәте генералларының погоннарында алтынланган металл эмблемалар; ветеринария хезмәте генералларының погоннарында да шундый ук, ләкин көмешләнгән эмблемалар.

Погонның зурлыгы: озынлыкка 14—16 сантиметр, киңлеккә 6,5 сантиметр. Медицина һәм ветеринария хезмәте генералларының погоны 4,5 сантиметр киңлектә.

III. ӨЛКӘН ҺӘМ УРТА КОМАНДИРЛАР СОСТАВЫНЫҢ ПОГОННАРЫ ҺӘМ АЕРЫМЛЫК БИЛГЕЛӘРЕ

Кыр погоны—хаки төсендәге сукнодан, көндәлек погон алтынсыман ефәктән яки алтын галуннан эшләнә. Инженер-команда составының, интендантлык, медицина һәм ветеринария хезмәте составының көндәлек погоны көмешсыман ефәктән яки көмеш галуннан ясала.

Урта дәрәҗәле командирлар составының погоннарында бер просвет һәм көмешләнгән металл йолдызлар бар, өлкән командирлар составы погоннарында ике просвет һәм шундый ук, ләкин зуррак күләмдәге йолдызлар. Погондагы йолдызларның саны хәрби дәрәҗәгә туры килә. Пехота командирларыннан тыш командирлар составы погоннарында, гаскәрләр төренә, хезмәткә карап, көмешләнгән эмблемалар куела.

Инженер-команда, интендантлык һәм медицина хезмәте составының погоннарындагы эмблемалар һәм йолдызлар алтынланган.

Хәрби ветеринария составы погоннарында йолдызлар алтынланган, эмблемалар көмешләнгән.

Погоннарда уртасына урак һәм чүкеч рәсеме ясалып йолдыз куелган, алтынланган, формалы төймәләр.

Кантларның һәм просветларның төсе, гаскәрләр төренә (хезмәткә) карап, түбәндәгечә:

Гаскәр төрләре	Кыр погоннары		Көндәлек погоннар	
	Кантның төсе	Просветларның төсе	Кантның төсе	Просветларның төсе
Пехота	Малиновый	Бордо	Малиновый	Малиновый
Артиллерия	Кызыл	Бордо	Кызыл	Кызыл
АБТ гаскәрләре	Кызыл	Бордо	Кызыл	Кызыл
Авиация	Зәңгәр	Бордо	Зәңгәр	Зәңгәр
Кавалерия	Ачык күк	Бордо	Ачык күк	Ачык күк
Инженерлык - техник гаскәрләр	Кара	Бордо	Кара	Кара
Интендантлык хезмәте	Малиновый	Коричневый	Малиновый	Малиновый
Инженер команда составы	Гаскәрләр төренә карап	Коричневый	Гаскәрләр төренә карап	Гаскәрләр төренә карап
Медицина һәм ветеринария хезмәте	Кызыл	Коричневый	Кызыл	Кызыл

Погонның зурлыгы: озынлыкка 14—16 сантиметр, киңлеккә 6 сантиметр, хәрби медицина һәм хәрби ветеринария составы погоннарының киңлеге 4 сантиметр.

IV. КЕЧЕ КОМАНДИРЛАР, РЯДОВОЙЛАР СОСТАВЫНЫҢ ҺӘМ ХӘРБИ УЧИЛИЩЕЛАРДА УКУЧЫЛАРНЫҢ ПОГОННАРЫ ҺӘМ АЕРЫМЛЫК БИЛГЕЛӘРЕ

Кыр погоннары хаки төсендәге сукнодан, көндәлек погоннар гаскәрләрнең төренә карап төсле сукнодан эшләнә.

Кече командирлар составының погоннарында аларның хәрби дәрәҗәләренә туры килә торган нашивкалар бар. Рядовойлар составының погоннары нашивкасыз.

Кыр погоннары эмблемасыз һәм трафаретсыз, көндәлек погоннарда гаскәрләрнең төрләренә карап җиз эмблемалар һәм гаскәри частьны (берләшмәне) күрсәтә торган сары трафаретлар бар. Пехотаның көндәлек погоннары эмблемасыз.

Погоннарның, кантларның һәм нашивкаларның төсе, гаскәрләрнең төренә (хезмәткә) карап, түбәндәгечә:

Гаскәр төрләре	Кыр погоннары			Көндәлек погоннар		
	Погон төсе	Кант төсе	Нашивка төсе	Погон төсе	Кант төсе	Нашивка төсе
Пехота	Хаки	Малиновый	Бордо	Малиновый	Кара	Алтынсыман
Артиллерия		Кызыл	Бордо	Кара	Кызыл	Алтынсыман
АБТ гаскәрләре		Кызыл	Бордо	Кара	Кызыл	Алтынсыман
Авиация		Зәңгәр	Бордо	Зәңгәр	Кара	Алтынсыман
Кавалерия		Ачык күк	Бордо	Ачык күк	Кара	Алтынсыман
Техник гаскәрләр		Кара	Бордо	Кара	Кара	Алтынсыман
Медицина һәм ветеринария хезмәте		Куе яшел	Коричневый	Куе яшел	Кызыл	Көмешсыман
Стройдан тыш кече начальниклар составы		Гаскәрләр төренә карап	Коричневый	Гаскәрләр төренә карап	Гаскәрләр төренә карап	Көмешсыман

Погонның зурлыгы: озынлыкка 14—16 сантиметр, киңлеккә 6 сантиметр.

Хәрби училищеларда укучыларның погоннары көндәлек кенә. Погонның өсте кантлы кырые буйлап галун белән тегелгән. Галунның төсе стройдагы барлык команда училищелары өчен—алтынсыман, команда-техник, интендантлык, хәрби медицина һәм хәрби ветеринария училищелары өчен—көмешсыман. Курсантларның погоннарында, алтын трафарет белән, хәрби училищеның исеме күрсәтелә.

Погоннарда уртасына урак һәм чүкеч рәсеме ясалып, йолдыз куелган, формалы җиз төймәләр бар.

V. ХӘРБИ-ЮРИДИК ХЕЗМӘТТӘГЕ ЮГАРЫ НАЧАЛЬНИКЛАР СОСТАВЫНЫҢ ПОГОННАРЫ ҺӘМ АЕРЫМЛЫК БИЛГЕЛӘРЕ

Погон үзе генерал погоны галунына охшатып махсус рәвештә тукылган галуннан ясала. Кыр погоннарында галун хаки төсендәге ефәктән, көндәлек погоннарда—көмеш волокадан була.

Погоннарның кантлары кызыл төстә.

Погоннардагы йолдызлар һәм эмблемалар алтынланып, металлдан ясалганнар.

Йолдызларның саны һәм урнашуы хәрби дәрәҗәгә туры килә.

Төймәләре герблы, алтынланган.

Погонның зурлыгы: озынлыкка 14—16 сантиметр, киңлеккә 4,5 сантиметр.

VI. ХӘРБИ-ЮРИДИК ХЕЗМӘТТӘГЕ УРТА ҺӘМ ЮГАРЫ НАЧАЛЬНИКЛАР СОСТАВЫНЫҢ ПОГОННАРЫ ҺӘМ АЕРЫМЛЫК БИЛГЕЛӘРЕ

Кыр погоны хаки төсендәге сукнодан, көндәлек погон көмеш галуннан яки көмеш ефәктән ясала.

Урта начальниклар составы погоннарында бер просвет һәм алтынланган металл йолдызлар, өлкән начальниклар составы погоннарында ике просвет һәм шундый ук, ләкин зуррак күләмдәге йолдызлар. Йолдызларның саны хәрби дәрәҗәгә туры килә.

Кыр погоннарының канты кызыл төстә, просветлар коричневый төстә. Көндәлек погоннарның канты һәм просветлары кызыл төстә, эмблемалар—алтынланган.

Төймәләре уртасына урак һәм чүкеч рәсеме ясалып йолдыз куелган, формалы һәм алтынланган төймәләр.

Погонның зурлыгы: озынлыкка 14—16 сантиметр, киңлеккә 4 сантиметр.



«Кызыл Шәрык» заводында яңа, күмер кислотасы эшләү цехы оештырылды һәм эшкә җибәрелде. Монда күмер кислотасы производство калдыкларыннан җитештерелә һәм аның дәвалау өчен файдалы сыйфатлары бар. Әлегә кадәр Казанда күмер кислотасы эшләнми иде. Рәсемдә: яңа цех эшчесе иптәш С. Кокшина баллоннарга сыек күмер кислотасы тутыра.

К. Тахтеев фотосы.

ГЕРОИК КЫЗЫЛ АРМИЯБЕЗНЕҢ 25 ЕЛЛЫГЫН ПРОИЗВОДСТВОДА ЯҢ ЖИҢҮЛӘР БЕЛӘН КАРШЫЛЫЙК

Яңа йөкләмәләр

Батыр Кызыл Армиябезнең 2 еллыгы хөрмәтенә социалисти ярышны киң җәелдерү турынд Молотов исемендәге 172 нче номе лы завод коллективының хат 14 нче лентә-туку фабрикасы эшч ләре арасында яңа хезмәт энтузиа мы тудырды.

Цехларда зур күтәренкелек бел митинглар булып үтте.

—Кызыл Армиянең героик һөж менә без хезмәт фронтында һөжү не көчәйтеп ярдәм итик!—ди фа рика эшчесе иптәш Котова. һә ул нормаларны системалы рәвеш 120 процентка үтәргә сүз бир Әзерләү цехы мастеры ярдәмчес иптәш Трофимов социалисти ярышка барлык цехларны да чак рып, ялкынлы чыгыш ясый. Мит нгта шулай ук Гальперин, Благо Виземан, Каталан һәм бик күп ба ка иптәшләр чыгып сөйләделәр.

Фабрика коллективы Кызыл А миянең 25 еллыгы хөрмәтенә я конкрет йөкләмәләр алды. Ал арасында түбәндәге пунктлар бар

беренче квартал планын 27 н мартка арттырып үтәргә;

беренче сортлы продукция планга караганда 7 процент арты эшләп чыгарырга;

барлык эшчеләрнең дә үз норм ларын тутырып һәм арттыры үтәүләренә ирешергә;

эшләнеп чыгарыла торган изд лиенең бер данәсенә китә торга чимал расходын 4 процентка, же нең отходка чыгуын 40 процент киметергә;

хезмәт җитештерүчәнлеген 2 процентка күтәрергә;

стахановчыларның санын 20 пр центка арттырырга, алдынгы ст хановчылардан мастер ярдәмчелә әзерләү курслары оештырырга һ.

Коллектив хәзер бу йөкләмәләрн үтәү өчен барлык көчен бире эшли. Декабрь аенда фабрика планын 115,5 процентка үтәп чы кан иде. Яңа, өстәмә йөкләмәлә дә, һичшиксез, үтәләчәк. Бу берд коллектив Кызыл Армиянең 25 е лыгын яңа җиңүләр белән карш лар.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

7 нче ЯНВАРЬДАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

7 нче январьга каршы төндә безнең гаскәрләр Донның урта агымы районында, Сталинградтан көньяк-көнбатыштарак һәм көньяктарак, Үзәк фронтта һәм Төньяк Кавказда элекке юнәлешләрдә сугышлар алып баруны дәвам иттерделәр.

* * *

Сталинград районында безнең гаскәрләр аерым участокларда дошманга каршы ут сугышы һәм разведка алып бардылар. Заводлар районында штурм группалары дошманның берничә блиндажын алдылар. Сталинградтан төньяк-көнбатыштарак дошман берничә тапкыр чыгыш ясады. Безнең сугышчылар гитлерчыларның разведка группаларын төп көчләрдән аердылар һәм 200 гә якын немец солдатларын һәм офицерларын кырдылар. Икенче бер участокта безнең подразделениеләр, дошман позицияләренә атака ясап, 20 окопны алдылар. Пленныйлар алынды.

* * *

Сталинградтан көньяк-көнбатыштарак һәм көньяктарак безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр. Н-че часть сугышчылары төнлә белән дошман урнашкан урынга бәреп керделәр һәм кинәт атака ясап халык яши торган ике пунктны алдылар. Безнең сугышчылар штык һәм граналалар белән 200 гә якын гитлерчыны кырып ташладылар һәм 100 дән артык немец солдатларын плен алдылар. Икенче бер участокта безнең подразделениеләр 4 орудие, танкка каршы ата торган 6 мылтык, 200 винтовка, 20 кул пулеметы, 5 станоклы пулемет, 1.000 снаряд, 20.000 патрон һәм башка трофейлар кулга төшерделәр.

* * *

Донның урта агымы районында безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар. Н-че часть сугышчылары дошман тылына үтеп чыктылар һәм дошманның фронтка якынлашып килүче ярдәмче көчләрен тар-мар иттеләр. 400 немец солдаты һәм офицеры кырып ташланды. Трофейлар кулга төшерелде. Шулар арасында 48 автомашина, танкка каршы ата торган 12 орудие, 4 кыр орудиесе бар. Икенче бер участокта безнең гаскәрләр, дошманның каты каршылык күрсәтүенә дә карамастан, алга таба киттеләр һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар.

* * *

Үзәк фронтта безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар. Ржевтан көнбатыштагы районда Н-че часть, дошманның контратакасын кире кайтарып, 200 дән артык гитлерчыны юк итте. Иптәш Чернов командалыгындагы чаңгычыларның штурм группасы, кинәт һөҗүм ясап, халык яши торган бер пунктта немецлар гарнизонын туздырды. Сугыш нәтиҗәсендә бер ротага якын немец пехотасы кырылды, трофейлар кулга төшерелде һәм пленныйлар алынды.

* * *

Төньяк Кавказда безнең частьлар, гитлерчыларның каршылык күрсәтүен җиңеп, уңышлы рәвештә алга баралар. Халык яши торган зур бер пункт өчен булган сугышларда Н-че берләшмә 600 гә якын дошман солдатларын һәм офицерларын юк итте, 28 танк, 7 бронемашина, 160 автомашина, 21 орудие, 74 пулемет, 33 миномет, берничә сугыш припаслары һәм азык склады кулга төшерде. 200 дән артык дошман солдатлары һәм офицерлары плен алынды.

* * *

Сумы өлкәсендә хәрәкәт итүче партизаннарның бер отряды ике атна эчендә 300 гә якын немец-фашист басып алучыларны кырып ташлаган. Совет патриотлары немецларның бер казармасын һәм бер азык складын яндырганнар, 6 йөк автомобилен юк иткәннәр һәм бер тимер юл эшелонын юлдан чыгарганнар. Немец-фашист оккупантларга каршы сугышларда партизаннар 6 пулемет, 3 автомашина, 42 винтовка, 16 пистолет, сугыш припаслары төялгән 8 повозка һәм 42.000 патрон кулга төшергәннәр. Халык яши торган бер пунктта партизаннар немецларның төрмә сакчыларын үтергәннәр һәм гитлерчылар тарафыннан атылырга хөкем ителгән 7 совет гражданинын азат иткәннәр.

* * *

Немец-фашист кабахәтләр Краснодар шәһәрендә канлы суеш оештырганнар. Шәһәрнең бер районында бер совет кызы бер немец офицерын үтергән булган, чөнки бу офицер аны көчләргә маташкан. Гитлерчылар бандитны бик зурлап күмгәннәр. Шуның артыннан гражданнар халкын —хатын-кызларны һәм балаларны җәзалый башлаганнар. Алар йортларга барып кергәннәр һәм семьяларны тоташтан суеп чыкканнар. Фашист ерткычлар бер көн эчендә шәһәр халкыннан 300 дән артык кешене үтергәннәр.

АНГЛИЯНЕҢ „БРИТАНИЯ СУГЫШТА" ИСЕМЛЕ ФОТОКҮРГӘЗМӘСЕ АЧЫЛУ

Кичә Москваның галимнәр йортында чит илләр белән культура элемтәсе тоту буенча Бөтенсоюз җәмгыяте (ВОКС) «Британия сугышта» исемле фотокүргәзмә ачты. Күргәзмә ВОКС ка Бөек Британиянең СССР дагы илчелеге биргән материаллардан төзелгән. Күргәзмәне ВОКС председателе иптәш Кеменов ачты.

Күргәзмәне ачканда Бөек Британиянең СССР дагы ышанычлысы Баггаллей әфәнде, Британиянең хәрби миссиясе башлыгы генерал Майлс, Чит Ил Эшләре Халык Комиссариатының матбугат бүлеге мөдире, Америка илчелеге һәм Америка хәрби миссиясе членнары, Сугышучы Франция хәрби миссиясе башлыгы генерал Пети, чит ил хәбәрчеләре, совет җәмәгатьчелеге вәкилләре катнашты. (ТАСС).

ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ОТЛИЧНО ӘЗЕРЛӘНЕРГӘ

Тагын да югарырак уңыш алу өчен

Кызыл юл районының «Шурабаш» колхозы (председателе иптәш Сафин) 1942 нче елда югары иген уңышы алды. Игеннәрне урып җыюны билгеләнгән срокларда, һичбер югалтуларсыз башкарды. Шулай ук дәүләткә ашлык тапшыру планын да барлык культуралар буенча срогында үтәде.

Хәзер биредә киләсе елда тагын да югарырак иген уңышы алу өчен ныклы көрәш бара. Югары сыйфатлы орлык—мул иген уңышы алуның нигезе. Шуның өчен дә «Шурабаш» колхозы членнары яхшы сыйфатлы чәчүлек орлык әзерләүгә аеруча нык әһәмият бирәләр. Солы, борчак, җитен, вика, киндер орлыклары әзерләнгән инде.

Г. Шәрәфиева, М. Хәкимова, А. Салихова, Р. Мәгъсумов, З. Шакиров, Г. Галиуллина, Б. Юсупова һәм Х. Тимершина иптәшләр үткән елны дәүләткә ашлык тапшыруда һәм башка авыл хуҗалыгы эшләрендә зур тырышлык күрсәткәннәр инде. Алар быел тагын да тырышыбрак эшлиләр. Орлык чистартуда, кар тотуда һәм гомумән язгы чәчүгә әзерлекнең башка тармакларында һәркөн нормаларны бермә-бер арттырып үтиләр. Хәзер биредә кырга 120 тонна тирес чыгарылган һәм 272 гектар мәйданда кар тотылган инде.

Тырмаларның һәм сабаннарның да күпчелек өлеше ремонтланган. Ремонтның сыйфаты яхшы. Язгы чәчү вакыты өчен капчыклар да җитәрлек бар. Арбалар әзер. Г. Әскәров, С. Рәхимова, Н. Саттаров иптәшләр атларны бик яхшы итеп тәрбиялиләр.

Ф. МӘҢГӘРЛЕ.

АШЛЫК ТАПШЫРУ ПЛАНЫН ҮТӘДЕЛӘР

Красный бор районы колхозчылары батыр Кызыл Армиябезнең Сталинград, урта Дон һәм башка фронтлардагы уңышлы һөҗүмнәренә ашлык сугуны төгәлләү, дәүләткә ашлык тапшыруны көчәйтү белән җавап бирәләр. «Кызыл юл», «Кызыл йолдыз», «Муравей», «Лебединое озеро» колхозлары ашлык сугуны һәм дәүләткә ашлык тапшыруны тулысынча үтәделәр. Шулай ук Ворошилов исемендәге колхоз, «Кызыл агым», «Коммунар» һәм «Застрельщик» колхозларында да дәүләткә ашлык тапшыру планнары үтәлде.

ХӘЙРИ.

ӘЗЕРЛЕК УҢЫШЛЫ БАРА

КУКМАРА, 7 январь. (Телефон буенча). «Әсән елга» колхозында язгы чәчүгә әзерлек эше көннән-көн кызурак темп ала. Чәчүлек орлык барлык культуралар буенча тулысынча әзерләнеп куелган. Колхоз тимерчесе иптәш Гарифҗанов барлык авыл хуҗалыгы машиналарына ремонтны тәмамлады. Ул хәзер тимерчеләре булмаган колхозларга ярдәм итә. Кырга тирес чыгару, кар тоту кебек эшләр дә яхшы бара. Басуга 1.400 йөк тирес чыгарылды инде. Тирес чыгаруда эшләүче Г. Шакиров һәм Мәҗитев иптәшләр көнлек норманы 200 процентка үтәп баралар.

Г. ГАЛИЕВ.

Танклар һәм самолетлар төзү фондына

АНТИПОВ 16.000 СУМ БИРДЕ

ЧИСТАЙ, 7 январь. (Телефон буенча). Молотов исемендәге колхоз членнарының митингысы булды. Иптәш Сталинның котлау телеграммасы уңае белән үткәрелгән бу митингта колхоз председателе иптәш Антипов болай диде:

— Сөекле Кызыл Армиябез оборонадан һөҗүмгә күчте. Бу һөҗүм киләчәктә тагын да киңрәк җәелсен һәм дошманны тәмам тар-мар иткәнчегә кадәр шулай өзлексез һәм уңышлы дәвам итсен өчен без Кызыл Армиябезгә ярдәмне көннән-көн арттыра барырга тиешбез. Мин «Татарстан колхозчысы» исемле танклар колоннасы төзелешенә моннан элек 1.000 сум биргән идем. Иптәш Сталинның котлау телеграммасы миндә тирәнтен дулкынлану тудырды. Һәм мин бу телеграммага җавап итеп, самолетлар төзү фондына тагын 15.000 сум акча бирәм.

Иптәш Антипов хезмәт фронты инвалиды. Аның семьясында 7 кеше бар.

МАТБУГАТ КҮЗӘТҮ УРЫНЫНДА

Кызыл Байраклы завод газетасы

«Алга» газетасы зур заводларның берсендә чыгу ягыннан үз өстенә йөкләнгән бурычларны дөрес аңлап эш алып бара. Газетаның төп тематикасы—производство мәсьәләләре. Баш мәкаләләр, производство командирларының, партия, профсоюз оешмалары җитәкчеләренең, стахановчыларының чыгышлары, төп эчтәлекне тәшкил иткән башка материаллар һ. б.—бөтенесе дә нигездә әнә шул тематикага кайтып калалар. Газетаның һәрбер номерында «Бөтенсоюз социалистик ярышы» рубрикасы астында оператив материаллар бирелеп бара.

Газета производстводагы уңышларны, ярыш алдынгыларын аеруча тулы итеп күрсәтә. Бу хәл, заводның соңгы айларда яхшы эшләп килүен, ноябрь ае йомгаклары өчен Дәүләт Оборона Комитетының күчмә Кызыл Байрагын яулап алуга ирешүен исәпкә алганда, бик аңлаешлы. Заводта гүзәл кадрлар бар һәм аларның саны торган саен арта бара. Аларның исемнәрен һәм эшләрен популярлаштырып газета бик яхшы эшли.

Бөтенсоюз социалистик ярышы, Октябрь алды социалистик ярышы заводка аеруча зур җиңүләр китерде. Цехлар, мастерскойлар, группалар, бригадалар һәм аерым эшчеләр нормаларны, заданиеләрне, планнарны үтәүдә бик зур күрсәткечләр бирүгә ирештеләр. Менә күп мисалларның берсе: «Иптәш Максимов җитәкчелегендәге цех август аенда планын үти алмаган, моның белән күп цехларның эшенә комачаулык иткән иде. Цех коллективы социалистик ярышны киң күләмдә җәелдереп, бу кыенлыкны большевикларча җиңде. Бердәм эш, Кызыл Армиягә күбрәк продукция бирү теләге белән янү—коллективка сентябрь аенда алдынгы цехлар сафына басу мөмкинлеген бирде» (8 нче октябрь, №59). Заводта стахановчы мастерлар ярышы үткәрелә. Айлык заданиене 206 процентка үтәгән мастер Соколов группасы бу ярышта беренче урынны, 205 процентка үтәгән Ларионов группасы—икенче урынны алалар һ. б. Иптәш Андреев җитәкчелегендәге цех, Октябрь алды социалистик ярышына кушылып, сентябрь заданиесен 28 нче числога үтәргә йөкләмә алган. Нәтиҗәдә ул заданиене 27 нче сентябрьгә үтәгән. Нечаев, Фотеев, Кругляк участоклары айлык заданиене 25—26 нчы сентябрьгә үтәгәннәр. Комсомолец мастер иптәш Устинов җитәкчелегендәге комсомолецлар-яшьләр группасы, фронттагыча эшләп, планнарны һәр ай саен арттырып үтәп килә һ. б. Мондый мисаллар бик күп һәм алар газетада киң урын алып киләләр. Нәтиҗәдә, 6 нчы ноябрьда (Бөек Октябрьның 25 еллыгы көнендә) тулай йомгак ясала: завод коллективы үз өстенә алган йөкләмәләрне намус белән үтәп чыга (105,2 процент).

Газета экономия режимы мәсьәләренә дә җитәрлек урын бирә. Бу турыда баш мәкаләләр һәм аерым материаллар бар. Шулай ук яшь эшчеләр белән эшләү, аларның квалификацияләрен күтәрү, аларны стахановчылар, икейөзпроцентчылар итеп тәрбияләү мәсьәләләрен дә газета бик дәрес рәвештә үзенең төп тематикаларыннан берсе итеп алган. Яшь эшчеләрнең эшкә тырышып өйрәнүләре, мастерларның, карт эшчеләрнең аларны тырышып өйрәтүләре, бу мәсьәлә буенча карт һәм яшь эшчеләрнең чыгыш ясаулары газетада номердан номерга диярлек күренекле урын алып киләләр. Бу яктан яшь эшчеләрнең газета битләрендә үзләренең чыгышлары аеруча характерлы. 7 нче декабрь номерында, мәсәлән, производствога күптән түгел генә килгән яшь эшчеләрдән Суфия Габдерахманова, Диля Зиннәтуллина, Зимина иптәшләр кыска гына вакыт эчендә югары квалификация алып икейөзпроцентчылар булып үсеп җитүләре турында язалар. Яшь эшчеләрнең мондый чыгышлары газетада күп кенә урнаштырыла һәм бу шулай кирәк тә, әлбәттә.

Уйлап табу, рационализация мәсьәләре буенча да газетада материаллар бар. Заводта гомумән рационализация эше яхшы җәелгән. Завод рационализаторлары Октябрьның 25 еллыгына 2 миллион сум экономия бирергә йөкләмә алганнар. Бөек бәйрәм көнне бу йөкләмәнең үтәлешенә йомгак ясала: алар, үз өсләренә алган йөкләмәләрен арттырып үтәп, 2 миллион 400 мең сумлык экономия бирүгә ирешкәннәр. Газета бу алдынгы патриотларны укучылар алдында популярлаштыра: Румянцев, Пастухов, Бурмин, Лещинер, Осипов һ. б. Бер Румянцев үзе генә дә 200 мең сум экономия бирерлек 12 тәкъдим керткән.

Газетаның тагын да бер уңышлы ягы: завод коллективы фронтовиклар белән җанлы элемтә тота һәм ике арада алмашына торган индивидуаль һәм коллектив хатларга газетада күп кенә урын бирелә. Мондый хатларда фронтовиклар үзләренең уңышлары турында язалар һәм тылдагы иптәшләрен героик хезмәткә рухландыралар. Завод эшчеләре исә фронтка хезмәт фронтыннан рапорт бирәләр һәм тагын да яхшырак эшләргә, фронт өчен сугыш продукциясен торган саен күбрәк бирергә вәгъдә итәләр.

Газета техник яктан да яхшы чыга. Күпчелек материаллар кыска һәм конкрет итеп эшләнеп биреләләр. Газетаның һәрбер номеры уңайлы урнаштырылган рәсемнәр белән чыга. Газета тирәсенә язучы актив яхшы тупланган. Һәрбер номерында завод, цех, участок җитәкчеләре, стахановчылар, икейөзпроцентчылар еш кына рәвештә катнашалар.

Газетаның җитешсез ягы итеп шуны әйтергә кирәк: анда күбрәк уңышлар турында языла. Заводның аерым эш тармакларында җитешсезлекләр дә бар, әлбәттә. Алар турында һич тә онытмаска, эштә булган кимчелекләрне үз вакытында ачып салып, аларны бетерүдә завод җитәкчелегенә практик ярдәм күрсәтергә кирәк. Ә инде җитешсезлекләр турында язылган тәнкыйть материаллар газетада бик аз. Бу кимчелекләр дә, әлбәттә, бетерелергә тиеш.



Начальнигы Гинзбург һәм начальник урынбасары Ермаков иптәшләр булган госпитальдә Ватан сугышы инвалидларын яңа квалификациягә өйрәтү эше яхшы оештырылган. Рәсемдә: бухгалтерлар курсын отличнога тәмамлап чыгучылардан бер группа.

С. Парфенов фотосы.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

7 нче ЯНВАРЬДАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

7 нче январьда безнең гаскәрләр Донның түбәнге агымы районында, һөҗүмне дәвам иттереп, район үзәкләреннән Мартыновканы, Николаевскаяны, Романовскаяны, халык яши торган зур пунктлардан Мало-Хлоповскийны, Власовны, Вишневканы, Николаевны, Александровны, Ново-Петровскийны, Демковны, Зазерскийны, Кухтачевны, Вифлянцевны, Страховны, Шаминканы, Тапилинны һәм тимер юл станциясе Вальковоны алдылар.

Төньяк Кавказда безнең гаскәрләр район үзәкләреннән Степноены, Советскаяны, халык яши торган зур пунктлардан Соломенскоены, Сухая Падинаны, Северныйны алдылар.

Үзәк фронтта безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар.

* * *

6 нчы январьда безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның 5 танкысын, гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 120 гә якын автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 15 артиллерия батареясының утын бастырдылар, бер сугыш припаслары складын, бер ягулык складын шартлаттылар һәм бер батальонга якын дошман пехотасын таркаттылар һәм бер өлешен юк иттеләр.

* * *

Сталинградның заводлар районында безнең штурм отрядлары трофейлар кулга төшерделәр һәм пленныйлар алдылар. Штурм группаларының хәрәкәтләренә булышлык итеп, артиллеристлар дошманның 12 ут точкасын бастырдылар, 9 ДЗОТ ын һәм блиндажын җимерделәр. Сталинградтан көнбатыштарак һәм төньяк-көнбатыштарак мылтык һәм пулемет атышы һәм разведчикларның актив хәрәкәтләре булды. Н-че часть сугышчылары дошманны 20 окоптан бәреп чыгардылар, 150 гитлерчыны кырдылар, 6 пулемет, 145 винтовка һәм бер радиостанция кулга төшерделәр.

* * *

Сталинградтан көньяк-көнбатыштарак һәм көньяктарак безнең гаскәрләр, дошманның каршылык күрсәтүен җиңеп, алга киттеләр һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Н-че берләшмә частьлары халык яши торган бер зур пункт өчен каты сугышлар алып бардылар. Монда дошман яңа көчләр китерде. Шулар арасында СС частьлары бар. Совет сугышчылары немецларны ныгытмалардан бер-бер артлы бәреп чыгардылар, дошманның техникасын һәм җанлы көчләрен юк итәләр. Икенче бер участокта безнең частьлар немецларның әһәмиятле бер чикне саклап тора торган бер батальон пехотасын тар-мар иттеләр. 600 гә якын гитлерчы, 7 танк һәм 26 автомашина юк ителде. Пленныйлар алынды. 3 танк, 2 броневик, 18 автомашина, бер сугыш припаслары складын һәм башка трофейлар кулга төшерелде.

* * *

Донның урта агымы районында безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр. Кайбер участокларда дошман нык каршылык күрсәтә һәм контратакаларга күчә. Совет сугышчылары гитлерчыларның контратакаларын кире кайтаралар һәм уңышлы рәвештә алга баралар. Н-че часть сугышчылары ике көн эчендә ике батальонга якын немец пехотасын, 7 танкны, 2 бронемашинаны, сугыш припаслары төялгән 25 автомашинаны юк иттеләр. Мылтык һәм пулемет уты белән немецларның 2 самолеты бәреп төшерелде. Икенче бер участокта гвардияче частьлар чолганыштан чыгарга маташучы немецлар гарнизонының 12 атакасын кире кайтардылар. Совет гаскәрләре дошман гарнизонын торган саен кыса баралар. Хәзер гарнизон һәлакәткә дучар ителгән. Безнең сугышчылар немецларның бер пехота полкы командиры булган полковникны плен алдылар.

* * *

Үзәк фронтта безнең гаскәрләр үзләре алган позицияләрне ныгыттылар, ә көчләрнең бер өлеше белән дошманның контратакаларын кире кайтардылар. Великие Лукидан көньяк-көнбатыштарак Н че часть дошман пехотасының һәм танкларының зур көчләренең берничә контратакасын кире кайтарды. 400 дән артык гитлерчы, 3 самоход пушка, 2 миномет батареясы юк ителде, 16 танк сафтан чыгарылды.

* * *

Төньяк Кавказда совет гаскәрләре сугыша-сугыша алга киттеләр һәм халык яши торган 40 пунктны алдылар. Иптәш Бекасов командалыгындагы гвардияче танкистлар 300 гә якын дошман солдатларын һәм офицерларын юк иттеләр. Гвардияче лейтенант Буряшкинның, гвардияче өлкән лейтенант Полищукның танк экипажлары халык яши торган бер пунктка бәреп керделәр һәм дошманның ут точкаларын юк иттеләр. Безнең автоматчиклар гитлерчыларның чигенү юлларын кистеләр һәм бик каты бәрелештә 100 дән артык немец солдатларын һәм офицерларын кырып ташладылар. Совет частьларының ударлары астында чигенгәндә немецлар авылларны яндыралар, күперләрне шартлаталар, юлларга, землянкаларга һәм блиндажларга миналар куялар. Командиры иптәш Демин булган частьның саперлары 3 көн эчендә 2.000 нән артык мина таптылар һәм аларны зарарсызландырдылар.

* * *

Орел өлкәсендә хәрәкәт итүче, Чапаев исемендәге партизаннар отряды немецларның вак гарнизоннарына берничә һөҗүм ясаган һәм 53 гитлерчыны кырган. Совет патриотлары 80 ат, 3 пулемет, 32 винтовка һәм 7.000 патрон кулга төшергәннәр. «За родину» отряды партизаннарының бер группасы дошманның бер хәрби эшелонын юлдан чыгарган. Сугыш техникасы төялгән 6 вагон һәм 2 платформа җимерелгән.

* * *

Сталинград районында совет очучылары һәм зенитчиклары көн саен немецларның транспорт самолетларын атып төшерәләр. Соңгы вакытларда шактый күп санда немец очучылары плен алынды. Плен алынган күзәтче очучы обер-ефрейтор Пауль Шен болай диде: «Декабрь аенда безнең авиагруппа үзенең базасын Демьянскидан көньякка күчерде. Без Сталинград районында чолганып калган немец дивизияләренә сугыш припаслары һәм азык ташып тордык. Мин бер генә тапкыр очарга өлгердем. Икенче очуым бик күңелсез бетте. Совет истребителе безнең «Юнкерс—52» самолетын бәреп төшерде. Безнең самолетта, экипаждан тыш, 2 тонна икмәк тә бар иде. Мин тора торган отряд берничә көн эчендә барлык самолетларының яртысын югалтты. Чолганып калган немец гаскәрләренең хәле бик авыр. Солдатлар хәтта үлгән атларның да итен ашыйлар».

* * *

Ленинград өлкәсе, Пустошка авылы крестьяннарын немец-фашист кабахәтләр коточкыч төстә җәзалаганнар. Гитлерчылар бөтен халыкны өйләреннән куып чыгарганнар, соңыннан, аларның милекләрен талап бетергәч, өйләрне һәм каралтыларны яндырганнар. Палачлар колхозчы Копыловның, бригадир Ануфриевның һәм укытучы Решетниковның семьяларын суеп чыкканнар. Немецлар барлык олы кешеләрне мәҗбүри эшкә җибәргәннәр.

„Югары бүләкләрне тулысынча аклarбыз"

Фронт заказларын үтәүдә героик хезмәт үрнәкләре күрсәткәнлекләре өчен, Н-че заводның алдынгы эшчеләреннән, белгечләреннән, җитәкчеләреннән бер группа иптәшләр хөкүмәт тарафыннан орденнар һәм медальләр белән бүләкләнделәр.

Бүләкләнүчеләр арасында мастерлардан Рутковский, Сөнгатуллин, партоешма секретаре Гольман һ. б. иптәшләр бар. Алар Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнделәр. Стахановчы-формовщик иптәш Родионов Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән, цех начальнигы Регулянт, станокчы Ира Фичун «Почет Билгесе» орденнары белән бүләкләнделәр. Заводның баш металлургы иптәш Малаховский үзенең производствода техник камилләштерү чаралары үткәрүе белән илгә бер миллион сумнан артык экономия бирде. Иптәш Малаховский һәм шулай ук стахановчы Биктаһирова, бригадир Муренко иптәшләр «Хезмәттәге батырлык өчен» медале белән бүләкләнделәр.

Орденнар һәм медальләр белән бүләкләнү кебек бу шатлыклы хәбәр ишетелгәч тә цехларда зур күтәренкелек белән митинглар булып үтте. Орденлылар бөек Ватан сугышы фронты өчен булган хезмәт фронтында алда тагын да яхшырак эшләргә сүз бирделәр. Коллективның барлык эшчеләре, эшче хатын-кызлары һәм белгечләре үзләренең алдынгы иптәшләрен югары бүләкләр алулары белән чын күңелдән котладылар һәм хезмәттә алардан үрнәк алырга вәгъдә иттеләр.

— Югары бүләкләрне тулысынча акларбыз һәм фронт өчен, туган Кызыл Армиябез өчен тагын да күбрәк һәм күбрәк продукция бирербез!—митингларда чыгып сөйләүчеләр бердәм рәвештә шулай дип белдерделәр. Фронт участогы мастеры иптәш Сөнгатуллин үз участогының айлык планны срогыннан элек үтәгәнлеге турында рапорт бирде.

М. ШВАРЦЕР.

Оккупантларга каршы Европа халыкларының көрәше

Югославиядә партизан отрядлары хәзер Сана елгасының уң як ярында бик каты сугышлар алып баралар. Немец частьлары Сански Мост шәһәрендә чолганып алынган гарнизонга ярдәмгә үтәргә маташалар, ләкин бу маташулар уңышсыз чыга. Дошман шактый зур югалтуларга дучар ителгән.

Костайниц Сунья районында партизаннарның бер отряды оккупантларга һәм усташиларга каршы каты сугышлардан соң Маяр исемле тимер юл станциясен алган. Туздырылган фашистлар частьлары паникага бирелеп чигенәләр. Трофейлар кулга төшерелгән һәм пленныйлар алынган.

Партизаннарның актив хәрәкәтләре нәтиҗәсендә Хорватия белән Балкан илләре арасында тимер юл хәрәкәте тукталган.

Польшада да партизаннар хәрәкәте көчәя. Люблин һәм Келец районнары партизаннары аеруча актив хәрәкәт итәләр. Валдавск районында партизаннарның бер отряды урманда өч тәүлек буена немецларның бер батальонына каршы сугыш алып барган. Берничә дистә кешеләре үтерелгәннән соң немецлар чигенергә мәҗбүр булганнар.

Бельгиядә патриотлар группасы Лилль белән Куртре арасындагы тимер юлны шартлаткан. Һәлакәт нәтиҗәсендә бу юлда поездлар йөреше ике көнгә тукталып торган. Льеждагы күмер шахталарының берсендә патриотлар күтәрү корылмасын җимергәннәр. Антверпен якынында алар немецлар кулындагы бер складны юк иткәннәр.

(ТАСС).

ФРАНЦИЯДӘ ГИТЛЕРЧЫЛАРНЫҢ БАШБАШТАКЛЫГЫ

НЬЮ-ЙОРК, 6 январь. (ТАСС). Юнайтед Пресс агентлыгының хәбәр итүенә караганда, немецлар Виши «хөкүмәте» аппаратында «чистарту» үткәрәләр. «Ышанычсыз элементлар» барысы да аппараттан куылалар.

Немецлар Лавальга союзниклар белән теләктәш булган өчен урыннарыннан чыгарылырга тиешле эре чиновникларның исемлеген тапшырганнар. Шулардан 28 кеше эшеннән алынган инде.

Виши властьларының Париждагы вәкиле Де Бринон якын араларда, берничә «промышленность эксперты» белән берлектә, Берлинга китәчәк. Әйтүләренә караганда, аларның Берлинга барулары немецларның бөтен Франция промышленностен Гитлерның хәрби властьлары контроле астына, ә эшчеләрне Гитлерның хезмәт министрлыгы карамагына бирүне таләп итүләренә бәйләнгән.

РУМЫНИЯДӘ РИЗАСЫЗЛЫКНЫҢ ҮСҮЕ

ЛОНДОН, 6 январь. (ТАСС). Газеталар Румыниянең күп кенә шәһәрләрендә зур чуалышлар баруны хәбәр итәләр. Шушы көннәрдә Бухарестта, хөкүмәткә каршы чыгышлар ясауда гаепләнеп, 300 кеше кулга алынган. Халык һәркайда да Антонескуның политикасына үзенең ризасызлыгын ачыктан-ачык белдерә. Кайбер урыннарда Германиягә каршы демонстрацияләр булган.

Совет—Германия фронтыннан кайтучы яралы румын офицерлары Россиядә немецларның, әлбәттә, җиңеләчәген ачыктан-ачык сөйлиләр.

ЧИТ ИЛ ХРОНИКАСЫ

—Марсельдә немец офицерлары урнашкан гостиницага һәм немец солдатлары керен утырган кафэга бомбалар ташланган. Үлүчеләр һәм яралланучылар бар. Немец властьлары шәһәрдә гадәттән тыш хәл кертканнәр.

Җаваплы редактор урынбасары
ГАЛИМ РЯБКОВ.

Театрларда һәм киноларда

Зур драма театры. Бүген—көндезге 12 сәгатьтә—„Эзләнгән кеше", 7 сәгать 30 минутта—„Фронт".

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында 8 нче һәм 9 нчы январьга игълан ителгән спектакль икенче вакытка күчерелә.

Дәүләт циркы. Бүген чегән ансамбле катнашы белән зур цирк тамашасы. Кич 8 сәгатьтә башлана.

„Электро" художестволы яңа фильм — „Райком секретаре".

„Унион" —„Антон Иванович ачулана".

„Пионер" көндез — „Дуслар" кич—„Волга-Волга".

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор—АТС 73—27, редактор урынбасары—АТС 76—29. секретарь—АТС 79—29. Партия тормышы бүлегә 14—75, промышленность-транспорт һәм хатлар бүлеге АТС 75—55, авыл хуҗалыгы бүлеге АТС 76—14, типография 36—60.

ПФ 605 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФИЯСЕ № Заказ 36